**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 30 декабрь № 1025

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары ведомство буйсынуындагы медицина оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2012 ел, 25 апрель, 323 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары ведомство буйсынуындагы медицина оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2012 ел, 25 апрель, 323 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 ел, 18 июль, 611 нче, 2012 ел, 31 декабрь, 1183 нче, 2013 ел, 30 гыйнвар, 48 нче, 2013 ел, 11 май, 313 нче, 2013 ел, 29 июнь, 455 нче, 2014 ел, 10 гыйнвар, 2 нче, 2014 ел, 17 гыйнвар, 20 нче, 2014 ел, 28 май, 362 нче, 2014 ел, 27 июнь, 443 нче, 2014 ел, 25 август, 613 нче, 2014 ел, 6 октябрь, 726 нчы, 2014 ел, 10 октябрь, 752 нче, 2014 ел, 29 декабрь, 1050 нче, 2015 ел, 4 август, 565 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары ведомство буйсынуындагы медицина оешмалары һәм Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы ведомство буйсынуындагы аерым типлаштырылмаган учреждениеләр хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәдә:

Нигезләмәгә 1 нче кушымтаның 2 графасындагы 58 нче юлда «интернационалист сугышчылар һәм фаҗигалар һәм табигать бәла-казалары нәтиҗәләрен бетерүдә катнашкан һәм аларда зыян күргән затлар өчен тернәкләндерү үзәкләре» сүзләрен «Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы

эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгының Ш.С.Каратай исемендәге республика тернәкләндерү үзәге» сүзләренә алмаштырырга;

Нигезләмәгә 4 нче кушымтага түбәндәге эчтәлекле 19 пункт өстәргә:

| | | | |
|---|---|---|---|
| «19. | «Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгының Ш.С.Каратай исемендәге республика тернәкләндерү үзәге» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет сәламәтлек саклау учреждениесе | барлык хезмәткәрләр | 15»; |

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары ведомство буйсынуындагы медицина оешмаларының һәм Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы ведомство буйсынуындагы аерым типлаштырылмаган учреждениеләрнең гомумтармак эшче профессияләре һәм гомумтармак җитәкчеләр вазыйфалары һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәдә:

Нигезләмәгә 1 нче кушымтаның 2 графасындагы 19 нчы юлда «интернационалист сугышчылар һәм фаҗигалар һәм табигать бәла-казалары нәтиҗәләрен бетерүдә катнашкан һәм аларда зыян күргән затлар өчен тернәкләндерү үзәкләре» сүзләрен «Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгының Ш.С.Каратай исемендәге республика тернәкләндерү үзәге» сүзләренә алмаштырырга.

2. Бу карарның көче 2015 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокукый мөнәсәбәтләргә тарала, дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\1025.docx